**Милли белем бирү буена эшләнгән эшкә анализ**

2019/2020 нчы уку елында татар теле һәм әдәбиятыннан 5-11 сыйныфларда -2 укытучы, ә башлангычта – 2 башлангыч укытучысы белем бирде. Аларның барысы да югары педагогик белемле, 3 се I квалификацион категориягә, 1се югары категориягә ия.

2019/2020 нче уку елында мәктәп түбәндәге тема буенча “Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын укытуда сыйфатлы белем бирүгә ирешү” эш алып барды.

**Максат:** Милли белем һәм тәрбия бирү, шул исәптән татар теле һәм әдәбияты, татар халкы һәм Татарстан тарихы фәннәреннән белем сыйфатын күтәрү өчен шартлар тудыру, алган белемнәрне тормышта куллана алырлык социаль актив, толерант шәхес тәрбияләү.

**Бурычлар:**

укытучылар тарафыннан укучыларның коммуникатив белем һәм күнекмәләрен үстерүгә, алган белемнәрне контрольдә тотуга юнәлдерелгән яңа дидактик белемнәр системасын, технологияләрне һәм укыту методларын үзләштерү һәм куллану;

алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, куллану һәм тарату;

татар теле һәм әдәбияты буенча эшләнгән, федераль исемлеккә кертелгән дәреслекләр һәм укыту әсбаплары, методик кулланмалар белән эшләүне тәэмин итү;

мәктәптә милли үзәк эшчәнлеген башлап җибәрү;

укучыларның белем сыйфатын бәяләүнең төрле алымнарын активлаштыру;

укучыларда милли үзаң үстерү;

сәләтле балалар белән эшләү системасын булдыру;

яңа икътисади шартларда конкурентлыкка сәләтле, югары әхлаклы толерант шәхес тәрбияләү.

Алда торган максат һәм бурычларны үтәү өчен түбәндәге эш планнары булдырылды:

Еллык һәм айлык эш планы.

Укытучыларның методик берләшмәсенең эш планы.

РФ һәм ТРның “Белем бирү турындагы” Кануннарын, “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турындагы Татарстан Республикасы Законы”н тормышка ашыруга нигезләнеп, 2018-2019 уку елында мәктәптә татар теле һәм әдәбияты барлык сыйныфларда да (2-11) укытылды:

- 7-9 сыйныфларда – атнага 4 сәгать;
- 10-11 сыйныфларда– атнага 2 сәгать;
- 1,2,4,5,6 сыйныфларда – атнага 5 сәгать;
- 3 сыйныфта – атнага 6 сәгать.

2019-2020 нчы уку елында мәктәптә татар милләтеннән булган 48 укучы белем алды:

- башлангыч сыйныфларда-15 укучы,
- 5-9 сыйныфларда – 21,
- югары сыйныфларда -12.

Бу уку елында да төп максат – белем бирүнең сыйфатын арттыру, үзара тәҗрибә уртаклашу, укучылар һәм укытучылар өчен бердәм таләпләр һәм нормативларны билгеләү, аларның үтәлешенә нәтиҗә ясау.

Белем сыйфатына килгәндә, түбәндәге нәтиҗәләрне күрергә була:

| Уку елы | татар теле | әдәбият |
|---|---|---|
| 2016-2017 | 85% | 100% |
| 2017-2018 | 91% | 100% |
| 2018-2019 | 96% | 100% |
| 2019-2020 | 91% | 100% |

Ел дәвамында барлык сыйныфларда да укыту стандартлары, уку программалары, практик өлеш һәм таләп ителгән минимум үтәлде.
Укытучылар дәресләрен нәтиҗәле үткәрүдә информатика кабинеты мөмкинлекләреннән дә файдаландылар. Берничә кабинетта интерактив такта булу, татар теле һәм әдәбияты укытучыларына ярдәм булды.

**Укучылар белән эшнең нәтиҗәләре**

Татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадалар башта мәктәптә уздырылды, аннары 4-11 сыйныф укучылары республика олимпиадасының муниципаль этабында көч сынаштылар һәм 9 призлы урын яуладылар. Муниципаль этапта уңыш яулаучы бер укучы Республика күләмендә үткәрелгән олимпиада да катнашып призер булды.

2019/2020 нче уку елында татар теле һәм әдәбиятыннан укыту-тәрбия эшендәге төп контроль элементлары түбәндәгеләр иде:
татар теле һәм әдәбияты укытуның торышы
белем алуның сыйфаты
мәктәп документларының торышы
программа үтәлеше
төп курс һәм урта мәктәп буенча имтиханнарга әзерлекнең торышы һәм аны үткәрү
Контрольнең түбәндәге методлары: укытучы һәм укучыларның эшчәнлеген дәрестә күзәтү, дәресләргә керү һәм аларны анализлау, дәрестән тыш чараларны карау. Документацияне: журнал,дәфтәр, укучыларның көндәлекләрен тикшерү,чирек йомгаклары турында укытучылар белән сөйләшү, әңгәмә вакытында тупланган мәгълүматларны анализлау һәр чирек саен үз вакытында нәтиҗәле уздырылды. Һәрбер тикшерелгән юнәлеш буенча белешмә язылды,булган кимчелекләр буенча татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик берләшмә утырышларында уртага салып сөйләнде, индивидуаль әңгәмәләр үткәрелде.

Укучыларның белем сыйфатларын тикшерү буенча административ контроль: ярты еллык контроль эшләр; еллык йомгаклау контроль эшләр (күчеш буенча), чыгарылыш имтиханнары үткәрү.

Традиция буенча 2019/2020 нче уку елында 21 нче февраль Туган тел көне буларак билгеләп үтелде. Уку елы дәвамында укучылар төрле бәйгеләрдә катнашып, уңышларга ирештеләр.
Уку елы барышында укучыларның иҗат эшләре “Сабантуй” һәм “Чистай хәбәрләре” газетасында басылып чыктылар.
Уку елы барышында МБнең план буенча каралган барлык утырышлары да, теоритик семинарлар да нәтиҗәле үтте. Анда оештыру эшләре, укыту-тәрбия мәсьәләләре, контроль эшләр һәм олимпиада нәтиҗәләре, йомгаклау контроль эш биремнәре һ.б. каралды, укытучыларның төрле проблемаларны яктырткан чыгышлары тыңланды. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Хамидуллина И.Ә., Хаматгалимова А.С. район һәм республика күләмендәге семинар, конференцияләрдә чыгыш ясадылар.
**Нәтиҗә**: 2019/2020 нче уку елында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эше канәгатьләнерлек дип табылды.
**Тәкъдимнәр**:
Татар теле һәм әдәбияты укытучыларына уку-укытуның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан заманча дәрес үткәрү юлларын тагын да нигезле өйрәнергә, заманча технология һәм чараларны актив файдаланып эшләргә.

Киләсе 2020/2021 нче уку елына бурычлар:
- ел дәвамында үз белемеңне күтәрү, алдынгы тәҗрибәне уртаклашу өстендә эшләргә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен оештырыла торган семинар-практикумнарда, квалификация күтәрү курсларында булырга;

-2020/2021 нче уку елы буена укучыларның татар теле һәм әдәбияты буенча белем дәрәҗәләрен күтәрү, иҗади мөмкинлекләрен үстерү өстендә даими системалы эш алып барырга;
- уку-укыту эшчәнлегендә инновацион технологияләрне, Сингапур укыту алымнарын югары дәрәҗәдә кулланырга;
-профессиналь конкурсларда актив катнашырга;
-укучыларның фәнни-гамәли конференцияләрдә, конкурсларда катнашуын тәэмин итәргә;
- сәләтле балаларны олимпиадаларга әзерлек эшен уку елы башыннан башлап, системалы рәвештә алып барырга.

## Милли белем бирү буенча эш планы

**Методик тема:** Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын укытуда сыйфатлы белем бирүгә ирешү.
**Максат:** Милли белем һәм тәрбия бирү, шул исәптән татар теле һәм әдәбияты, татар халкы һәм Татарстан тарихы фәннәреннән белем сыйфатын күтәрү өчен шартлар тудыру, алган белемнәрне тормышта куллана алырлык социаль актив, толерант шәхес тәрбияләү.
**Бурычлар:**
укытучылар тарафыннан укучыларның коммуникатив белем һәм күнекмәләрен үстерүгә, алган белемнәрне контрольдә тотуга юнәлдерелгән яңа дидактик белемнәр системасын, технологияләрне һәм укыту методларын үзләштерү һәм куллану;
алдынгы педагогик тәҗрибәне өйрәнү, куллану һәм тарату;
татар теле һәм әдәбияты буенча эшләнгән, федераль исемлеккә кертелгән дәреслекләр һәм укыту әсбаплары, методик кулланмалар белән эшләүне тәэмин итү;
мәктәптә милли үзәк эшчәнлеген башлап җибәрү;
укучыларның белем сыйфатын бәяләүнең төрле алымнарын активлаштыру;
укучыларда милли үзаң үстерү;
сәләтле балалар белән эшләү системасын булдыру;
яңа икътисади шартларда конкурентлыкка сәләтле, югары әхлаклы толерант шәхес тәрбияләү.
**Төп эш юнәлешләре:**
мәгарифне үстерү институты һәм Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү үзәге каршында оештырыла торган юнәлешле һәм авторлык курсларында системалы рәвештә белемнәрне күтәрү;
алдынгы педагогик тәҗрибәне җыю, туплау һәм тарату, республика һәм район бәйгеләрендә актив катнашу;
яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда укучыларны кызыксындыра алырлык эш алымнарын (компьютерда эшләү, мультимедиа, эзләнүчәнлек, проектлар методы, интерактив такта һ.б.) актив файдалану;
сәләтле балалар белән эшләү системасын камилләштерү;
укучыларны бердәм республика һәм дәүләт имтиханнарына эзлекле әзерләү;
Методик –оештыру эшчәнлеге.

Педагогик кадрлар белән эш.

| № | Чаралар | Вакыты | җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Укыту программаларын тормышка ашыруда укыту-методик һәм дидактик комплексларны сайлау буенча консультация үткәрү | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |
| 2 | Эш планын төзү:<br>татар теле һәм әдәбияты укытучыларының ММБ педагогик осталык мәктәбе | сентябрь | Хусаинова А.Р. Загидуллина Г.Ә. |
| 3 | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының мәгълүмат банкын булдыру | Август сентябрь | Хусаинова А.Р. |
| 4 | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының ММБ эшен планлаштыру | август | Хусаинова А.Р. Загидуллина Г.Ә. |
| 5 | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының планнарын өйрәнү | август | Хусаинова А.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6 | Мәгариф бүлеге өчен отчетлар кабул итү һәм тапшыру | сентябрь | Хусаинова А.Р. |
| 7 | методик берләшмә утырышлары<br>ММБнең 2019-2020 уку елына методик эш нәтиҗәләре белән таныштыру һәм 2020-2021 уку елына эш планын кабул итү.<br>уку елында кулланылачак дәреслекләр һәм программаларны раслау;<br>бердәм орфографик таләпләр кабул итү.<br>“Яңа технологияләрнең шәхесне формалаштырудагы роле”<br>укытучыларның документларын карау;<br>норматив-хокукый документлар белән эшләү;<br>педагогик хезмәткәрләрне аттестацияләү һәм аттестация үткәрү мәсьәләләре.<br>Сәләтле балалар белән эшләү үзенчәлеге.<br>Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын укытуда инновацион һәм мәгълүмати технологияләрне куллану.<br>Татар теле дәресләрендә укучыларның танып белү эшчәнлеген оештыру. | Сентябрь<br><br>Ноябрь<br><br>Гыйнвар<br><br>Март | Хусаинова А.Р.<br>Загидуллина Г.Ә. |
| 8 | Педагогик кадрларны аттестацияләү буенча документлар белән эш, 2019-2020 нчы уку елында аттестация узучы укытучыларның исемлеген барлау. | сентябрь | Хусаинова А.Р. |
| 10 | МҮИнда һәм Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү үзәгендә укытучыларның квалификациясен күтәрү | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |
| 11 | Индивидуаль консультацияләр | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |
| 12 | Иҗади отчетлар оештыру | Апрель-май | Хусаинова А.Р. |
| 13 | Укытучыларның һөнәри газета-журналларына даими язылып баруларын контрольдә тоту | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р.<br>Гарифуллина Л.Ф. |
| 14 | Укытучыларның иҗат лабораторияләрен баету өстендә эшне дәвам итү һәм төрле конкурсларда катнашу | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |
| 15 | Ризаэддин Фәхреддин укуларында катнашу | гыйнвар | Хусаинова А.Р. укытучылар. |
| 16 | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының “Мастер-класс” республика бәйгесенең район турын үткәрү, республика турында катнашу | Февраль-апрель | Хусаинова А.Р. |
| 17 | Бөтенроссия “Туган тел” форумында катнашу | апрель | Хусаинова А.Р. |

Аттестация узучы укытучылар белән эш

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Укытучыларны аттестация үтү буенча норматив документлар белән таныштыру | октябрь | Хусаинова А.Р. |
| 3 | Укытучыларның һөнәри эшчәнлекләрен өйрәнү | декабрь | Хусаинова А.Р. |
| 4 | Аттестацион документларны тутыру | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |

Укучылар белән эш

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Фән бәйгеләренең мәктәп һәм муниципаль турын | Октябрь - | Хусаинова А.Р. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тиешле дәрәҗәдә оештыру | ноябрь | |
| 2 | Республикада оештырылучы төрле фәнни – гамәли укуларда катнашуны тәэмин итү. | Сентябрь - май | Хусаинова А.Р. |
| 3 | “Белем җәүһәрләре” бәйгесендә катнашу | Октябрь | Хусаинова А.Р. |
| 4 | “Туган телем шагыйрьләр теле” фәнни гамәли конференциядә катнашу | Ноябрь | Хусаинова А.Р. |
| 5 | Татар теленнән Халыкара олимпиадада катнашу | ноябрь-апрель | Хусаинова А.Р. татар теле укытучылары |
| 7 | Ризаэддин Фәхреддин укуларында катнашу | гыйнвар | Татар теле укытучылары |
| 15 | Туган телләр айлыгы кысаларында конкурслар, төрле чаралар үткәрү | Февраль-апрель | Боерык, нигезләмә |
| 16 | Татар театрларына бару, спектакльләр карауны оештыру | Ел дәвамында | Боерык, нигезләмә |

Сәләтле укучылар белән эш

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Мәктәпләртә татар теле һәм әдәбияты фәне буенча сәләтле укучыларның исемлеген һәм алар белән эш планын булдыру | сентябрь | Хусаинова А.Р. Татар теле укытучылары |
| 2 | Сәләтле укучылар белән эшләү тәҗрибәсен өйрәнү һәм тарату | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |
| 3 | Сәләтле укучыларны район күләмендә уздырыла торган фән олимпиадаларында, фәнни конференцияләрдә катнаштыру | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. Татар теле укытучылары |
| 4 | БРТна әзерлек планын булдыру һәм план нигезендә системалы эшләү | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. Татар теле укытучылары |
| 5 | Сәләтле укучыларның мәкаләләрен һәм башка төрле иҗади эшләрен вакытлы матбугатта урнаштыру | Ел дәвамында | Татар теле укытучылары |

Аналитик-тикшерү һәм диагностикалау эшчәнлеге

| № | Өйрәнеләсе сораулар тематикасы | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Укытучыларның эш программаларын өйрәнү | сентябрь | Хусаинова А.Р. |
| 2 | Уку программаларының үтәлешен һәм мәктәп документациясенең алып барылышын өйрәнү | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |
| 3 | Мәктәпнең яңа уку елына әзерлеген өйрәнү:<br>Матди укыту базасы, кабинетлар торышы, кадрлар белән тәэмин итлеш | август | Хусаинова А.Р. |
| 4 | Язма эшләр, срезлар үткәрү | Ел дәвамында | Хусаинова А.Р. |

Мәгълүмати-аналитик эшчәнлек

| № | Чаралар | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Август конференциясендә татар теле һәм әдәбияты укытучылары секциясендә катнашу. | август | Татар теле укытучылары |
| 2 | Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының семинарларын, мастер-классларын үткәрү:<br>“Заманча дәрес төзү ” | Декабрь-январь | Хаматгалимова А.С. Хамидуллина И.Ә. |
| 3 | Программаларны һәм телгә караган башка документларны өйрәнү | системалы | Хусаинова А.Р. |
| 5 | Үткәрелгән өйрәнүләр буенча белешмәләр төзү һәм нәтиҗәләрен яктырту | системалы | Хусаинова А.Р. |